# җөмлә кисәкләре члены предложения

- Ия
- Хәбәр
- Аергыч
- Тәмамлык
- Хәл

- Подлежащее
- Сказуемое
- Определение
- Дополнение
- Обстоятельство

# Ия
# Подлежащее

**Кем? Нәрсә?**

- Көймә килә- эзе юк.
- Кызыл сиңа килешә.
- Ун кешегә тигез бүленә.
- Юраган юш килә.
- Бу- шәп түгел.
- Аһ-ваһлар бетте хәзер.

**Кто? Что?**

- Исем
- Сыйфат
- Сан
- Фигыль
- Алмашлык
- Ымлык

# Хәбәр Сказуемое

## Нишли? Нишләде?

**гади**

- Киңәшле эш таркалмас.
- Дөнья матур, дөнья киң!
- Ни кирәк?
- Кем бу?

**кушма**

- Шуннан башланды инде.
- Хәзер минем хәл башка иде.
- Тыныч кына укып булмый аны.
- Әскый карт үзе ахырдан сөйләп йөрде.

# Аергыч

**Нинди? Кайсы? Кемнең? Нәрсәнең? Ничә? Ничәнче?**

- Җанга урын тапмас чаклар була.
- Пристаньдагы халык ярга чыгып баскан.
- Билгеле, бу кап-кара урманда һәр ерткыч та бар.

# Определение

**Какой? Который?Чей? Чья? Сколько? Который?**

- Аергыч ияне, хәбәрне, тәмамлыкны, хәлне ачыклый.
- Аергычлар исем, сыйфат, сан, алмашлык, фигыль, рәвеш, хәбәрлек сүзләр белән белдереләләр.

# Тәмамлык

## Дополнение

Кемгә?
Нәрсәгә?
Кемне?
Нәрсәне?
Кемнән?
Нәрсәдән?
Кемдә?
Нәрсәдә?
Кем белән?
Нәрсә белән?

- Туры тәмамлык
- Кыек тәмамлык

- Җәй көнен яздым бераз;языйм әле кыш, көзләрен (туры).
- Без бу кыз белән ничектер ансат кына танышып киттек(кыек).

# Хәл
# Обстоятельство

**Кайда? Кайчан? Ни өчен?**

- Урын хәле
- Вакыт хәле
- Рәвеш хәле
- Күләм хәле
- Сәбәп хәле
- Максат хәле
- Шарт хәле
- Кире хәл

**Где? Когда? Для чего?**

- Остоятельства места
- Обстоятельства времени
- Обстоятельства образа действия
- Обстоятельства меры
- Обстоятельства причины
- Обстоятельства цели
- Обстоятельства условия
- Обстоятельство уступительности

# Урын хәле

Кайда?

Кая?

Кайдан?

- Паркта һичкем юк.
- Бер бәләкәй болыт үтте безнең утрау өстеннән.
- Без шунда  иртә таңнан җәяүләп китәбез.

# Вакыт хәле

Кайчан?

Кайчанга чаклы?

Кайчаннан бирле?

- Ул көнне кич гомуми торакта сүз  шулар турында гына барды.
- Өч көннән соң мин аны шәһәр вокзалыннан озатып калдым.
- Әмма хәзер мин аны сөйләп бирмичә булдыра алмыйм.

# Сәбәп хәле

Ник?

Ни өчен?

Ни сәбәпле?

- Шуңадыр инде бик тыйнак булырга… тырышалар иде.
- Карт кешене рәнҗеткән өчен бугазы өзелмәсен дип теләк теләде.
- Бүген килеп төшүчеләр өч-дүрт кенә булганлыктан, безне кабул итү озакка сузылмады.

# Максат хәле

Ни өчен?

Нинди максат белән?

Нигә?

- Киткән урманга утынга, ялгызы бер ат җигеп.
- Концерт бирергә шәһәрдән бик мәшһүр артистлар көткән идек.
- Орлыкка дип чүпләгәнебез менә монысы була.

# Рәвеш хәле

Ничек?

Ни рәвешле?

- Бүлмәдә пальтодан йөрергә ярамый.
- Ник, Мокамай, син тормышыңны чабатаңдай матур үрмәдең?!
- Нәфисә, мәйданга көрәшкә чыккан батырсыман, аякларын җәебрәк басты.

# Күләм хәле

Күпме?

Никадәр?

Ни дәрәҗәдә?

Ничә тапкыр?

- Җиде кат үлчә, бер кат кис.
- Козгынны бит өч йөз ел яши диләр.
- Көне-төне тырышып эшләгәнен ул әйтергә залга теләде.

# Шарт хәле

Нишләсә?

Нинди шартта?

- Кыек атып туры тия икән, бигрәк тә шәп.
- Кояшның нинди икәнен күрәсегез килсә, июлҗ аенда безнең авылга барыгыз.
- Инде дә килеп котыптан бер дулкын көньякка таба уздымы, ул безгә туп-туры килә.

# Кире хәл

Нишләсә дә?

Нәрсәгә карамастан?

- Ә син кат-кат әйтә торып та язмый калдыргансың.
- Әмма ләкин, вакыт- вакыт әнә шулай ярсып китүемә карамастан, мин аны ничек тә аңларга тырышам.
- Ә беләсеңме, күргәндә дә әйтми торган кешеләр була бит.